КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 октябрь г.Казань № 1292

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 661 нче; 2006 ел, 1 март, 87 нче; 2006 ел, 21 апрель, 198 нче; 2006 ел, 9 июнь, 293 нче; 2007 ел, 18 май, 196 нчы; 2008 ел, 15 июль, 509 нчы; 2009 ел, 5 июнь, 360 нчы; 2009 ел, 17 август, 551 нче; 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы; 2010 ел, 14 октябрь, 808 нче; 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче; 2011 ел, 15 ноябрь, 935 нче; 2012 ел, 22 август, 726 нчы; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 18 февраль, 110 нчы; 2013 ел, 7 март, 152 нче; 2013 ел, 27 апрель, 286 нчы; 2013 ел, 10 август, 558 нче; 2014 ел, 21 апрель, 261 нче; 2015 ел, 1 июнь, 397 нче; 2016 ел, 10 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 13 декабрь, 925 нче; 2017 ел, 6 март, 127 нче; 2017 ел, 26 май, 309 нчы; 2017 ел, 14 ноябрь, 867 нче; 2018 ел, 4 июль, 545 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1107 нче; 2018 ел, 14 декабрь, 1135 нче; 2019 ел, 16 апрель, 301 нче; 2019 ел, 21 май, 416 нчы; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 13 июль, 576 нчы; 2019 ел, 12 октябрь, 907 нче; 2020 ел, 10 февраль, 83 нче; 2020 ел, 18 май, 400 нче; 2020 ел, 28 май, 436 нчы; 2020 ел, 13 июль, 577 нче; 2020 ел, 10 октябрь, 917 нче; 2020 ел, 27 октябрь, 962 нче; 2020 ел, 2 декабрь, 1087 нче; 2021 ел, 31 август, 790 нчы; 2022 ел, 1 апрель, 306 нчы; 2022 ел, 16 июнь, 567 нче; 2022 ел, 22 декабрь, 1395 нче; 2023 ел, 10 гыйнвар, 2 нче, 2023 ел, 06 март, 221 нче,

2023 ел, 02 июнь, 676 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

7 пунктта «2006 елга» сүзләрен «тиешле финанс елына һәм план чорына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы нигезендә.»;

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчада:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә дәүләт капитал салулары, капиталь ремонт программаларын җаваплы башкаручы функцияләрен, шулай ук финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган объектларны төзүнең, реконструкцияләүнең һәм капиталь ремонтлауның дәүләт заказчысы функцияләрен башкара;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасында зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту, җирләү эшен оештыру буенча методик тәкъдимнәрне раслый.»;

3.3.4 пунктчада:

ундүртенче абзацта «тоту максатларында» сүзләрен «, кулланганда һәм карап тотканда кулланыла торган» сүзләренә алмаштырырга;

уналтынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин